# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№ 1** **25 ноябрь 2020 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Туйкә авыл җирлеге составына керүче
Туйкә авылында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 24 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

« Сез, 2021 елда Түйкә авыл җирлеге Түйкә торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 (Дүрт йөз) сум күләмендә, 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 200 (Ике йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1. Туйкә авылында күмү урыннарны карап тоту (куаклар һәм агачлар кисү, үлән чабу, чүп-чар җыештыру, контейнерлар сатып алу һәм урнаштыру);

2. Туйкә авылында урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (урам утлары, яктырткычлар, махсус җайланмалар сатып алу, урнаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтү, килешү буенча эшләр өчен түләү);

3. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

3.1 Туйкә авылында тракторчыга карны механикалаштырылган җыю буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

3.2 Туйкә авылы территориясендә үлән чабу (җәй көне эш өчен түләү),

4. Түйкә авылында халыкны су белән тәэмин итүне ,ташландык суларны агызуны оештыру (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру, эчәргә яраклы суга биохимик һәм бактериологик анализ үткәрү, килешү буенча эшләр өчен түләү);

5. Туйкә авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк, сувенир продукция сатып алу, «Җиңү көне», «Сабантуй», «авыл бәйрәме», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү) ;

6. Туйкә авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар ( янгын гидрантларын сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм карап тоту, килешү буенча хезмәт өчен түләү);

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 340 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны - 184 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 184 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге составына керүче Туйкә авылында узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: « Сез, 2021 елда Түйкә авыл җирлеге Түйкә торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 200 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1. Туйкә авылында күмү урыннарны карап тоту (куаклар һәм агачлар кисү, үлән чабу, чүп-чар җыештыру, контейнерлар сатып алу һәм урнаштыру);

2. Туйкә авылында урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (урам утлары, яктырткычлар, махсус җайланмалар сатып алу, урнаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтү, килешү буенча эшләр өчен түләү);

3. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

3.1 Туйкә авылында тракторчыга карны механикалаштырылган җыю буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

3.2 Туйкә авылы территориясендә үлән чабу (җәй көне эш өчен түләү),

4. Түйкә авылында халыкны су белән тәэмин итүне ,ташландык суларны агызуны оештыру (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру, эчәргә яраклы суга биохимик һәм бактериологик анализ үткәрү, килешү буенча эшләр өчен түләү);

5. Туйкә авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк, сувенир продукция сатып алу, «Җиңү көне», «Сабантуй», «авыл бәйрәме», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү) ;

6. Туйкә авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар ( янгын гидрантларын сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм карап тоту, килешү буенча хезмәт өчен түләү);

.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы, Җәлил ур.,19 йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы Гагарин ур., 4а йорт.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Туйкә авыл җирлеге Башлыгы Закирова Р.Р.